**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3054**
**17.04.2023**

Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2836 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 15 июнендәге 2836 номерлы карары (Башкарма комитетның 2022 елның 9 августындагы 4006 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәренең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программалар максатларыннан һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәт максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.»;

2) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары максатчанлыгының критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына һәм (яки) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисадый сәясәт максатларына туры килүе;

2) ташламаларга хокуктан файдаланган түләүчеләр санының һәм ташламалар куллануга потенциаль хокукка ия түләүчеләр санының яки 5 еллык чорда

түләүчеләрнең гомуми санының нисбәте белән характерлана торган ташламаларга түләүчеләр тарафыннан ихтыяҗ булу.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарлары Н.А. Кропотовага, А.С. Ганиевка, Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ә.Р. Кондрабаевага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов